**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 октябрь № 759

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 ноябрь, 899 нчы карары белән расланган Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 ноябрь, 899 нчы карары белән расланган Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән, инвестицияләр җәлеп итү өлкәсендә чаралар үткәрүне һәм Татарстан Республикасының конгресс-күргәзмә эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыра;»;

15 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү турында килешүдә субсидиянең зурлыгы, аның максатчан билгеләнеше, субсидиянең хисап финанс елында файдаланмаган өлешен агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Агентлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия

алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруына субсидия алучының ризалыгы (субсидия алучы дәүләт (муниципаль) унитар предприятие, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый берләшмәләр катнашында хуҗалык иптәшлеге һәм җәмгыяте, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре катнашында коммерциячел оешмалар булган очраклардан тыш); алынган акча исәбеннән чит ил акчасын сатып алуны тыю карала, югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал һәм комплектлаучы эшләнмәләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук бу акчаларны бирү максатларына ирешү белән бәйле субсидия бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларда билгеләнгән бүтән операцияләрдән тыш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\759.docx